| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>КУШМАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КОШМАН АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08.05.2024 ел Кошман ав. № 76

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 октябрендәге 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 31 октябрендәге 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 9 статьяның 4 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 12 абзац өстәргә:

««Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр төзи, аларга федераль бюджет акчалары (дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) капитал салуларны финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы булып тора.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://kushman-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Кайбыч муниципаль районы
Кошман авыл җирлеге Башлыгы Л.Р. Сафина